КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 апрель г.Казань № 344

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Чит илләрдә яшәүче ватандашларны ирекле рәвештә күчерү хисабына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм демографик үсешенә ярдәм итү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенә чит илләрдә яшәүче ватандашларны ирекле рәвештә күчерүгә ярдәм итү чаралары турында» 2006 елның 22 июнендәге 637 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «2019-2021 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын дәүләт заказчысы – дәүләт программасы координаторы һәм аны гамәлгә ашыру барышын контрольдә тоту буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1117 нче; 2018 ел, 11 июнь, 458 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1002 нче; 2019 ел, 5 март, 156 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «34. | Чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә ярдәм итү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасы икътисадының квалификацияле кадрларга ихтыяҗларын тәэмин итүгә һәм аларның кытлыгын киметүгә булышлык күрсәтү, шул исәптән актуаль фәнни һәм технологик проблемалар белән шөгыльләнүче белгечләрне һәм галимнәрне җәлеп итү; Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының мәшгульлегенә, шул исәптән авыл җирлегендә эшкә урнашу юлы белән дә булышлык күрсәтү; Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларны |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | һәм аларның гаилә әгъзаларын ирекле рәвештә күчерүгә ярдәм итүче социаль-икътисадый һәм мәгълүмати шартларны оештыру, Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль хезмәтләр күрсәтү». |

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин